Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге Советы

Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

25 февраль, 2026 ел № 4

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлауларны бетерү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлегенең 2017 елның 21 августындагы 60 номерлы (2017 елның 12 декабрендәге 73 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 84 номерлы, 2019 елның 20 сентябрендәге 121 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 55 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 62 номерлы) карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1.Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә:

- Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Татар Казысы авыл җирлеге, Рус Казысы авылы, Луговая ур. адресы буенча урнашкан 16:33:110201:57 кадастр номерлы, 36140 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Татар Казысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) «дини йолаларны башкару» файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 27 февраленнән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы Ф. Г. Кәримуллин